ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 32 от 12.02.2019

**Апас муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә мәгълүмат системасының эшчәнлегем һәм куллану Тәртибенең 3.1 пунктына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларны үзгәрешләр кертү турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 30 июнендәге 768 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты **карар итте**:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 17 мартындагы 86 карары белән расланган Апас муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә мәгълүмат системасының эшчәнлегем һәм куллану Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 нче пунктының 2нче пунктчасының 5нче абзацын көчен югалткан дип санарга;

3.1 нче пунктының 3нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3)контракт системасы турында Федераль законда каралган электрон документларга кул кую өчен көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куллану.»;

3.1 нче пунктының 4нче пунктчасын көчен югалткан дип санарга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хоккый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырырга һәм Апас муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары Ш.Ш. Гаффаровка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Н. Гыйбадуллин**